**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» сентябрь, 2022 ел № 675

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 21 мартындагы 211 номерлы карары белән расланган «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда каралган бурычларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген үтәү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 833 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Шәхси белешмәләр турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 30 статьясындагы ундүртенче өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 14 июлендәге 266-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 21 мартындагы 211 номерлы карары белән расланган «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда каралган бурычларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген үтәү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 833 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертү хакында:

- 4 пунктта түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:

«9.1) «Шәхси мәгълүматлар турында» 152-ФЗ номерлы РФ Федераль законының 18.1 статьясында билгеләнгән бурычларны оператор тарафыннан башкару ысуллары турында мәгълүмат; ».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://www.-pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Хәбибуллин